Укучыларның иҗади һәм индивидуаль сәләтләрен үстерү һәрбер укытучының бурычы. Уен,әкиятләр аша баланың сәләте ачыла һәм үсә. Элеккеге ,без яратып укыган, әкиятләрне заманча үзгәртеп сәхнәләштерсәң, укучы балаларга бик кызык була һәм алар үзләре теләп катнашалар. «Заманча Шалкан» әкияте дә шул нияттән эшләнелгән.

« Заманча  Шалкан»  әкияте.

Ролләрдә:

1.Шалкан

2.Әби (шау-шулы,күп сөйләшә торган)

3.Бабай (тыныч кына,әз сүзле)

4.Кыз (татар халык киеменнән, тыйнак кыз)

5.Акбай (шаян)

6.Мыраубикә (ялкау)

7.тычкан Джерри (солдат киеменнән)

Сәхнә заманча бизәлгән.Өй тора,агачлар (гөлләр),көймә.Татарча көй уйный.(барыня көенә)

Шалкан бии-бии чыга. Бер кат сәхнә әйләнәсендә биеп ала да ,сәхнәнең уртасына килеп баса.

Шаулап әби чыга.Шалканны күрә:

- Бу ни бу? (аптырый) Шалкан  ничек  зур  булып үскән. (бабайга дәшә) Бабай, бабай, син  кайда, ник шалканны  тартып чыгармыйсың? (ачуланып бабайны эзли китә)

(русский танец-сударыня көенә) Бабай ,әкрен генә, чыга. Шалканны күреп:

- Ай-һай (башын  каршый, уйланып өйри).

Бабай әбигә дәшә:

-Әби,әби, әйдә шалканны тартыш.Кил,булыш.Синсез булмый бер эш.

Әби (ачуланып,сүгә-сүгә):

-Нәрсә инде? Шуны да минсез эшли алмыйсыңмыни ?

Шалканны таталар,тарталар тартып чыгара алмыйлар.

Әби кесәсеннән телефон ала:

-Кызга дәшик әле. (телефонга тертә-тертә)нәрсә булды бу телефонга? Карале,кызыбыз тагын инстаграмда утыра ахрысы,телефоны алмый.(ачулана).

(Ф.Тямаев. «Алыштырмам сине беркемгә» көенә)

Кыз бии-бии чыга.

- Нәрсә булды?

Бергәләп биеп алалар һәм әби белән бабай:

-Әйдәле, кызым, бергәләп шалканны тартып чыгарыйк әле.

Шалканны тарталар,тарталар тартып чыгара алмыйлар. Шуннан кыз Акбайга дәшергә була:

-Акбай , Акбай, кил әле, булыш зинһар.

(Собака бывает кусачей көенә) Акбай өрә-өрә, бии-бии чыга:

-Ни бар, (өрә) нәрсә булды?

Кыз Акбайга булышырга әйтә. Шалканны тарталар,тарталар тартып чыгара алмыйлар. Акбай Мыраубикәгә дәшә:

-Мыраубикә,Мөраубик килче, булышчы.

(карак песи көенә) Мыраубикә мырылдый-мырылдый,койрыгын селки-селки,чыга:

-Мрр,ни бар,нәрсә булды?

Бергәләп булышырга әйтәләр. Шалканны тарталар, тарталар тартып чыгара алмыйлар. Тычкан Джеррига чират килеп җитә. Мыраубикә:

- Джерри, Джерри кил әле.Булыш ,зинһар.

(С.Сәйдәшев Марш көенә) тычкан Джерри килеп чыга. Джерри шалканны бер кулы белән генә тарта һәм шалкан килеп чыга.Шуннан соң барысы да

куаналар,бергәләп (М.Вагизов «Солдатта булган диләр» көенә) ,бии-бии,тычканга күрсәтә-күрсәтә, анны мактап, җыр җырлыйлар.

Ахырда ( Ф.Тямаев. «Алыштырмам сине беркемгә» көенә) шалканны алып,бергәләп сәхнәдән чыгып китәләр.